РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**ИСПОЛКОМ**
**Кирельского сельского поселения**
***Камско-Устьинского***
**муниципального района**

Улица Гагарина , дом 1, Камско-Устьинский район, 422827, телефон 8(277)- 3-67-45. ИНН-1622004725 ОГРН-1061672020453 ОКАТО-92230830000 ЛБ-222160029 р/с 40204810100000420010 ГРКЦ НБ РТ г.Казань БИК-049205001 КПП-162201001

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
***Кама Тамагы***
**муниципаль районы**
**ИСПОЛКОМ**
**Кирельского сельского поселения**

Гагарина Ур, Кама-Тамагы, районы, 422827,телефон 8 (277)-367-45. ИНН-1622004725 КПП-162201001 ОГРН-1061672020453 ОКАТО-92230830000 ЛБ-222160029 р/с-40204810100000420010 ГРКЦ НБ РТ г. Казань БИК 049205001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**30 январь 2020 ел** **№ 1**

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кирельск авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр кыйммәтен раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, «Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2020 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында" 2019 елның 29 гыйнварындагы 61 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кирельск авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кирельск авыл җирлегендә № 1 Кушымта һәм № 2 кушымта нигезендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә 6124,86 сум күләмендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кирельск авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кирельск авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә

күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында» гы 2019 елның 10 апрель кабул ителгэн 21 нчы номерлы  карарын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны  түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмати стендларда халыкка җиткерергә:

- Кирельск авылы, Гагарин урамы, 1 (административ бина)
- Кирельск авылы  Гагарин ур., 14 (кибет «Раифа»)
- Кирельск авылы  Түбән урамы д. 6 (китапханә)
- Ишем авылы, Үзәк урамы, 10 нчы йорт (авыл клубы),
- Мордва Каратай авылы , Үзәк урамы, 7 нче йорт (бина КФУ);

һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар 2020 елның 1 февраленнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Кама Тамагы муниципаль районы
Кирельск авыл җирлеге башлыгы,
Кама Тамагы муниципаль районы
Кирельск авыл җирлеге Советы Рәисе Ф.Я.Зиннәтуллин

Кушымта № 1
Татарстан Республикасы Кама
Тамагы муниципаль районы
Кирельск авыл җирлеге
Башкарма комитеты карарына
кушымта
№ 1 «30» гыйнвар 2020 ел

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кирелҗск авыл җирлегендә 2020 елның 1 февраленнән алып җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлегенең бәяләре

| **Хезмәт күрсәтү исеме** | **Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда.)** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Күмү өчен табут һәм башка кирәк булган предметларны китереп бирү | 3670,18 |
| 3. Зиратка үлгән кешенең мәетен китеру | 522,27 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1932,41 |
| **Барысы** | **6124,86** |

Кушымта № 2
Татарстан Республикасы Кама
Тамагы муниципаль районы
Кирельск авыл җирлеге
Башкарма комитеты карарына
кушымта
№ 1 «30» гыйнвар 2020 ел

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кирельск авыл җирлегендә 2020 елның 1 февраленнән алып җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлегенең бәяләре

| **Хезмәт күрсәтү исеме** | **Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда.)** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Тәнне каплау | 188,35 |
| 3. Җирләү җыелмасы –Кэфенлек, такта комплекты, җирләү өчен кирәкле предметларны бирү һәм китерү | 3481,83 |
| 4. Зиратка үлгән кешенен мәетен китерү | 522,27 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1932,41 |
| **Барысы** | **6124,86** |